Татарстан Республикасы  Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Кариле авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

28  декабрь 2019 ел                                                          № 136

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге Советының “Җирле салымнар һәм җыемнар буенча пенялар, штрафлар недоимкалары һәм бурычларын түләтү һәм исәптән чыгаруны өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен раслау турында” гы 2019  елнын 18 ноябрендэге 134 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында»

Россия Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты нигезендә № 54-ТРЗ от 19.07.2017 ел, № 54-ТРЗ «Региональ салымнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тану өчен өстәмә нигезләр билгеләү турында», 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы һәм, җирле салымнар һәм җыемнар буенча бурычларны түләттерүгә,  «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карары:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге Советының “Җирле салымнар һәм җыемнар буенча пенялар, штрафлар недоимкалары һәм бурычларын түләтү һәм исәптән чыгаруны өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен раслау турында” гы 2019  елнын 17 октябрендэге 119 нчы карарына тубэндэге үзгәрешләр кертергэ:

карарның 1 пунктындагы 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3) 2007 елның 2 октябрендәге 229 - ФЗ номерлы “Башкарма производство турында” Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 һәм 4 пунктларында каралган нигезләр буенча башкарма җитештерүне тәмамлау турында суд приставы-башкаручы тарафыннан карар чыгарылуга бәйле рәвештә башкарма документлар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны мәҗбүри түләттерү мөмкинлеге булмау;»;

карарның 1 пунктындагы 4  пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4) үлгәннәрнең яки вафат булучыларның пенялары һәм штрафлары буенча бурычлары, варисларның мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас алмаган очракта, мирас ачылганнан соң өч ел дәвамында Россия Федерациясе Граждан-процессуаль законнары белән билгеләнгән тәртиптә булу.»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән нигезләр булганда, җирле салымнар буенча недоимканы түләттерүгә өметсез дип тану, бу салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурычлар булуын раслаучы документлар булып тубэндэгелэр торалар:

1) салым гамәлдән чыгарылу турындагы норматив хокукый акт турында белешмәләр (исеме, номеры, датасы);
2) тулэтеп булмаслык недоимка суммалары, пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычлар турында салым органы белешмәсе.;
3) 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы «Башкарма производство турында" Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 һәм 4 пунктларында каралган нигезләр буенча башкарма документны түләтүчегә кире кайтарганда суд пристав-башкаручысы карарының күчермәләре»;
4) физик затларның Граждан хәле актларын теркәүне гамәлгә ашыручы орган тарафыннан Россия Федерациясе Салым кодексының 85 статьясындагы 3 пункты нигезендә салым органына кергән үлем фактын теркәү турында белешмәләр»;
5) мираска хокук турында таныклык бирү турында белешмәләрнең булмавы турында салым органы белешмәсе.».

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Олы Кариле авылы, Пионер ур., 1;

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Чаллы авылы, Ленин ур., 43,

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Кече Кариле авылы, Вахитов ур., 16, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Олы Кариле

авыл җирлеге башлыгы, Татарстан
Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районыОлы Кариле
авыл җирлеге Советы рәисе Ф.Г. Гарифуллин